РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«29» сентябрь 20 21 ел г. Альметьевск № 1360

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районы ветераннарына (пенсионерларына) социаль ярдәм өлкәсендә агымдагы эшчәнлекне тәэмин итү өчен «Әлмәт муниципаль районы ветераннарының (пенсионерларының) җирле иҗтимагый оешмасы» коммерциягә карамаган оешмасының Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 елның 15 апрелендәге 536 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тәкъдимнәре нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районы ветераннарына (пенсионерларына) социаль ярдәм өлкәсендә агымдагы эшчәнлекне тәэмин итү өчен «Әлмәт муниципаль районы ветераннарының (пенсионерларының) җирле иҗтимагый оешмасы» коммерциягә карамаган оешмасының Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 елның 15 апрелендәге 536 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карар исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы ветераннарына (пенсионерларына) социаль ярдәм өлкәсендә эшчәнлек алып баручы коммерциягә карамаган оешмага Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында»;

карарның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы ветераннарына (пенсионерларына) социаль ярдәм өлкәсендә эшчәнлек алып баручы

Зак. № 305-2000

коммерциягә карамаган оешмага Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга (1 нче кушымта).»;

карарга 1 нче кушымтада:

1 нче кушымтаның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы ветераннарына (пенсионерларына) социаль ярдәм өлкәсендә эшчәнлек алып баручы коммерциягә карамаган оешмага Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе»;

1 нче кушымтаның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Тәртип уставта билгеләнгән агымдагы эшчәнлекне финанс белән тәэмин итү максатларында муниципаль учреждение булмаган коммерциягә карамаган оешмага Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү шартларын билгели (алга таба - субсидияләр, Учреждение).»;

1 нче кушымтаның 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4Финанслау чыганагы - район башкарма комитетының резерв фонды (алга таба - резерв фонды) булган субсидияләр түбәндәгеләргә җибәрелә:

төрле чараларда катнашу, оештыру;

Учреждение эшчәнлеген тәэмин итү өчен коммуналь хезмәтләр һәм агымдагы чыгымнар өчен түләү.»;

1 нче кушымтаның 8 пунктындагы 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гаризаны кабул итеп алган һәм теркәгән көннән алып 5 эш көне эчендә район башкарма комитеты аңа кушымта итеп бирелгән документларны һәм бүлеп бирелгән акчаларның күләме, аларны тоту максатлары яисә район башкарма комитетының структур бүлекчәсе әзерләгән акчаларны бүлеп бирүнең максатчанлыгы турында бәяләмәне карый һәм субсидия бирү турында яисә аны бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.»;

1 нче кушымтаның 10 пунктында «(алга таба - Килешү)» сүзләреннән соң «резерв фондтан субсидияләр рәвешендә акчалар бүлеп бирү турында район башкарма комитеты күрсәтмәсенә кул куйганнан соң» сүзләрен өстәргә.»;

1 нче кушымтаның 14 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Хисап аеннан соң килүче айның 10 нчы числосына кадәр тиешле чыгымнарны уздырганнан соң, Учреждение район башкарма комитетына һәм Финанс-бюджет палатасына чыгымнарны гамәлгә ашыру турында Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Финанс - бюджет палатасы тарафыннан билгеләнгән Килешүнең типовой формасы буенча хисап тапшыра, аларны финанс белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия тора.».

2. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова А.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А.Н. Подоваловка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы — А.Н. Подовалов

ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ